ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 31 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2025 елның 29 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 31 статьясындагы 1 өлешенең $6^1$ пунктына (2005 елның 25 октябрендәге 106-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 1; 2005, № 10 (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 3, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 10 (II өлеш); 2011, № 5, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 96 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш), № 48 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2024, № 18 (I өлеш), № 47 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 79 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«$6^1$) дәүләт хезмәткәренең мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылуына, мобилизация буенча Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләренә хезмәткә җибәрелүенә яисә мобилизация чорында, хәрби хәл чорында яисә сугыш вакытында хәрби хезмәт узу турында контракт йә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә яисә Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә ихтыярый ярдәм күрсәтү хакында контракт төзүенә бәйле рәвештә Федераль законның $53^1$ статьясында каралган гарантияләр;».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2025 ел, 11 ноябрь
№ 78-ТРЗ